| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ПОПОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ПОПОВКА<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2018 с. Поповка № 90

Поповка авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020,
2021 еллар план чорына бюджеты турында

Поповка авыл җирлеге Советы карары:
1 Статья 1.
1. 2019 елга Поповка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4532,8 мең сум.;
2) Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4532,8 мең сум.;
3) Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум.
2. 2020 елга һәм 2021 елга Поповка авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:
1) 2020 елга Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4632,5 мең сум һәм 2021 елга 4767,6 мең сум күләмендә.;
2) 2020 елга Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4632,5 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 113,7 мең сум күләмендә һәм 2021 елга 4767,6 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 234,0 мең сум күләмендә.;
3) 2020 елга Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум һәм 2021 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2020 елның 1 гыйнварына Поповка авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча-0 мең сум.

2. 2021 елның 1 гыйнварына Поповка авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.
3. 2022 елның 1 гыйнварына Поповка авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.
4. Поповка авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычның иң чик күләмен билгеләргә:
1) 2019 елга 0 мең сум;
2) 2020 елга 0 мең сум;
3) 2021 елга 0 мең сум.
3 Статья
Поповка авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.
4 Статья
1. Поповка авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Поповка авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.
5 Статья
1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Поповка авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм

төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.
3.Поповка авыл җирлеге бюджетының 2019 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен 0 мең сум күләмендә, 2020 елга 0 мең сум күләмендә, 2021 елга 0 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга.

6 Статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча 2019 елга 1402,6 мең сум күләмендә, 2020 елга 1455,9 мең сум күләмендә, 2021 елга 1514,1 мең сум күләмендә.
2. 2019 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә кирәк.

7 Статья

Баулы муниципаль районы бюджетыннан 2019 елда 2628,9 мең сум күләмендә, 2020 елда 2733,4 мең сум күләмендә, 2021 елда 2861,3 мең сум күләмендә дотацияләрне расларга.

8 Статья

Поповка авыл җирлеге бюджетында Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне 2019 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу өчен 83,9 мең сум, 2020 елда 85,1 мең сум, 2021 елда 88,3 мең сум күләмендә расларга.

9 Статья

1. Җирле үзидарә органнары 2019 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

10 Статья

Поповка авыл җирлеге бюджеты акчалары Поповка авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактларның 2018 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2019 елда Поповка авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

11 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Поповка авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

12 Статья

1. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Поповка авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район Башлыгы, Совет Рәисе
Поповка авыл җирлеге башлыгы С. А. Попов